Татарстан Республикасында зурлар арасында беренчел авыру очракларының түбәнәюе түбәндәге класслар буенча күзәтелә: яңа шеш авырулары – 27,2 процентка, кан, кан ясагыч органнар авырулары һәм иммунитет механизмын җәлеп итә торган кайбер бозылулар – 24,8 процентка, җәрәхәтләр, агуланулар һәм тышкы сәбәпләрнең кайбер башка зыяннары – 19,1 процентка, нерв системасы авырулары – 2 процентка.

2024 елда республикада зурларның беренчел авырулар саны структурасында:

сулыш органнары авырулары 51,3 процент (Россия Федерациясендә – 56,6 процент) тәшкил итә;

җәрәхәтләр һәм агуланулар – 5,7 процент (Россия Федерациясендә – 4,9 процент);

нерв системасы авырулары – 3,8 процент (Россия Федерациясендә – 4,1 процент);

сөяк-мускул системасы һәм тоташтыргыч тукыма авырулары – 3,5 процент (Россия Федерациясендә – 3,8 процент).

2024 елда Татарстан Республикасында 15 – 17 яшьлек балаларның беренчел авыруы (тормышта беренче тапкыр куелган диагноз белән) 100 мең кешегә 144 310 очрак тәшкил итте, бу уртача Россия күрсәткеченнән 1,6 процентка түбәнрәк.

Анализлана торган чорда (2015 – 2024 еллар) республикада 15 – 17 яшьлек балалар арасында беренчел авыру очраклары үсеш тенденциясенә ия: 2015 ел

дәрәҗәсенә карата 0,8 процентка.

Беренчел авырулар саны түбәндәге класслар буенча: сулыш органнары авырулары – 29,8 процентка, кан, кан ясагыч органнар авырулары һәм иммунитет механизмын җәлеп итә торган кайбер бозылулар – 0,5 процентка, нерв системасы авырулары – 0,1 процентка арту күзәтелә.

15 – 17 яшьлек балалар арасында беренчел авырулар санының түбәнәюе түбәндәге класслар буенча күзәтелә: яңа шешләр – 21,1 процентка, кан әйләнеше системасы авырулары – 28,1 процентка, сөяк-мускул системасы һәм тоташтыргыч тукыма авырулары – 28,7 процентка, җәрәхәтләр, агуланулар һәм тышкы сәбәпләрнең кайбер башка зыяннары – 27,2 процентка, тумыштан килгән аномалияләр (үсеш кимчелекләре), деформацияләр һәм хромосома бозылулары – 14,2 процентка.

2024 елда 15 – 17 яшьлек балаларның беренчел авыру структурасында сулыш органнары авырулары алдынгы урынны алып тора – 55 процент (Россия Федерациясендә – 57,1 процент, 2023 ел мәгълүматлары).

9 нчы таблица

## Балалар арасында авыруларның таралуы (15 – 17 яшь) (тиешле яшьтәге 100 мең кешегә)

| Авырулар классларының исеме | АХК-10 буенча коды | Юл саны | Территория | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| Барлык авырулар, шулардан: | A00 – T98 | 1 | Россия Федерациясе | 224 725,9 | 225 781,7 | 220 740,8 | 219 504,7 | 218 432,7 | 201 046,7 | 217 320,9 | 231 505,5 | 233 016,8 | мәгълүматлар юк |
| | | 2 | Идел буе федераль округы | 254 644,7 | 251 573,3 | 247 566,1 | 245 018,2 | 243 459,3 | 222 042,0 | 245 958,1 | 259 513,3 | 267 455,8 | мәгълүматлар юк |
| | | 3 | Татарстан Республикасы | 241 055,1 | 240 361,5 | 255 097,1 | 253 032,8 | 257 316,9 | 247 805,5 | 269 086,9 | 276 054,7 | 278 303,7 | 27 1112,7 |
| Яңа шеш авырулар | C00 – D48 | 4 | Россия Федерациясе | 1 032,4 | 1 034,6 | 1 083,6 | 1 142,9 | 1 177,7 | 1 077,0 | 1 165,9 | 1 241,7 | 1 305,7 | мәгълүматлар юк |
| | | 5 | Идел буе федераль округы | 1 051,8 | 1 024,5 | 1 093,4 | 1 166,7 | 1 212,6 | 1 042,3 | 1 128,3 | 1 200,5 | 1 323,3 | мәгълүматлар юк |
| | | 6 | Татарстан Республикасы | 822,4 | 746,4 | 1 093,2 | 1 093,6 | 919,2 | 922,4 | 1 202,0 | 1 125,4 | 1 198,1 | 1 257,6 |
| Кан, кан ясагыч органнар авырулары һәм иммунитет механизмын җәлеп итә торган кайбер бозылулар | D50 – D89 | 7 | Россия Федерациясе | 1 921,9 | 1 973,2 | 1 905,6 | 1 880,3 | 1 876,9 | 1 672,3 | 1 775,6 | 1 871,0 | 1 970,5 | мәгълүматлар юк |
| | | 8 | Идел буе федераль округы | 2 224,8 | 2 281,8 | 2 354,6 | 2 402,9 | 2 313,4 | 2 262,2 | 2 351,3 | 2 585,7 | 2 718,6 | мәгълүматлар юк |
| | | 9 | Татарстан Республикасы | 2 884,6 | 2 734,2 | 3 080,1 | 3 516,5 | 3 798,7 | 4 229,1 | 4 178,9 | 4 413,1 | 4 655,9 | 4 142,5 |
| Нерв системасы авырулары | G00 – G98 | 10 | Россия Федерациясе | 12 542,5 | 12 426,3 | 12 301,8 | 12 226,0 | 12 242,2 | 10 996,3 | 11 651,5 | 11 976,4 | 12 285,3 | мәгълүматлар юк |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 11 | Идел буе федераль округы | 15 794,8 | 15 520,2 | 15 030,9 | 15 029,0 | 14 875,7 | 13 394,3 | 14 391,6 | 15 040,6 | 1 599,5 | мәгълүматлар юк |
| | | 12 | Татарстан Республикасы | 13 887,4 | 13 206,8 | 13 299,3 | 13 618,6 | 13 569,0 | 12 771,2 | 13 475,4 | 14 451,3 | 14 732,4 | 13 818,9 |
| КӘСА – кан әйләнеше системасы авырулары; | I00 – I99 | 13 | Россия Федерациясе | 5 477,0 | 5 470,8 | 5 357,1 | 5 166,0 | 5 148,2 | 4 623,6 | 4 679,2 | 4 851,9 | 4 896,0 | мәгълүматлар юк |
| | | 14 | Идел буе федераль округы | 7 036,3 | 6 922,1 | 6 775,9 | 6 452,0 | 6 232,1 | 5 713,1 | 5 744,7 | 5 657,9 | 6 113,3 | мәгълүматлар юк |
| | | 15 | Татарстан Республикасы | 10 063,7 | 9 563,5 | 11 101,3 | 10 656,0 | 10 018,2 | 10 138,2 | 10 566,2 | 10 190,0 | 10 301,1 | 9 715,3 |
| Сулыш органнары авырулары | J00 – J98 | 16 | Россия Федерациясе | 75 886,7 | 79 569,6 | 77 652,5 | 77 712,2 | 76 406,6 | 74 344,6 | 80 333,2 | 86 072,2 | 90 873,8 | мәгълүматлар юк |
| | | 17 | Идел буе федераль округы | 83 941,5 | 84 876,7 | 84 400,5 | 84 118,6 | 82 563,5 | 79 777,9 | 89 497,5 | 94 256,9 | 102 288,6 | мәгълүматлар юк |
| | | 18 | Татарстан Республикасы | 71 185,7 | 70 999,5 | 75 643,4 | 76 525,8 | 76 705,3 | 79 349,3 | 88 631,2 | 82 664,5 | 87 466,3 | 88 539,8 |
| Сөяк-мускул системасы һәм тоташтыргыч тукыма авырулары | M00 – M99 | 19 | Россия Федерациясе | 17 392,9 | 17 202,1 | 16 960,2 | 17 064,0 | 17 378,8 | 15 332,0 | 16 674,2 | 17 777,5 | 18 933,1 | мәгълүматлар юк |
| | | 20 | Идел буе федераль округы | 19 786,5 | 19 533,1 | 19 042,5 | 18 968,3 | 19 900,8 | 17 333,9 | 18 725,6 | 19 443,0 | 21 146,2 | мәгълүматлар юк |
| | | 21 | Татарстан Республикасы | 18 531,6 | 18 651,9 | 19 045,4 | 19 465,8 | 19 372,0 | 18 248,5 | 18 418,8 | 19 110,6 | 20 115,8 | 19 950,4 |
| Тумыштан килгән аномалияләр (үсеш кимчелекләре), деформацияләр һәм хромосома бозылулары | Q00 – Q99 | 22 | Россия Федерациясе | 2 377,5 | 2 441,2 | 2 430,5 | 2 381,7 | 2 394,9 | 2 266,8 | 2 282,9 | 2 355,6 | 2 518,6 | мәгълүматлар юк |
| | | 23 | Идел буе федераль округы | 2 970,7 | 3 079,0 | 3 146,4 | 3 061,8 | 3 193,6 | 3 331,2 | 3 125,1 | 3 295,0 | 3 611,2 | мәгълүматлар юк |
| | | 24 | Татарстан Республикасы | 2 416,5 | 2 293,2 | 3 469,0 | 3 249,3 | 3 443,6 | 3 436,7 | 3 570,7 | 3 650,6 | 3 867,9 | 3 687,6 |
| Җәрәхәтләнүләр, агуланулар | S00 – T98 | 25 | Россия Федерациясе | 17 547,4 | 17 476,7 | 17 393,5 | 17 438,6 | 17 564,5 | 14 037,2 | 14 709,9 | 15 362,4 | 15 621,4 | мәгълүматлар |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| һәм тышкы сәбәпләрнең кайбер башка зыяннары | | | | | | | | | | | | | юк |
| | | 26 | Идел буе федераль округы | 17 495,2 | 17 059,7 | 16 377,4 | 17 698,6 | 17 715,2 | 13 776,9 | 14 708,0 | 14 903,3 | 15 852,7 | мәгълүматлар юк |
| | | 27 | Татарстан Республикасы | 23 366,3 | 23 393,7 | 24 152,7 | 25 210,9 | 25 501,6 | 18 434,9 | 20 888,7 | 21 739,6 | 18 861,3 | 16 995,7 |

9 нчы һәм 10 нчы таблицаларда 100 мең кешегә исәпләгәндә балалар (15 – 17 яшь) арасында авыруларның таралышы һәм беренчел авыру очраклары турында мәгълүматлар китерелде.

10 нче таблица

Балалар (15 – 17 яшь) арасында беренче тапкыр авырулар саны
(тиешле яшьтәге 100 мең кешегә)

| Авырулар класларының исеме | АХК-10 буенча коды | Юл саны | Территория | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| Барлык авырулар, шулардан: | A00 – T98 | 1 | Россия Федерациясе | 137 383,8 | 137 273,8 | 136 018,6 | 136 020,1 | 134 601,1 | 122 743,3 | 137 106,4 | 14 9143,8 | 146 650,5 | мәгълүматлар юк |
| | | 2 | Идел буе федераль округы | 150 248,2 | 146 966,4 | 145 134,0 | 145 050,5 | 141 927,4 | 128 172,0 | 146 188,9 | 15 8215,8 | 159 357,0 | мәгълүматлар юк |
| | | 3 | Татарстан Республикасы | 143 099,5 | 134 546,3 | 144 201,4 | 147 004,1 | 150 646,9 | 135 188,2 | 151 671,4 | 15 5867,2 | 146 507,7 | 144 310,0 |
| Яңа шеш авырулары | C00 – D48 | 4 | Россия Федерациясе | 501,1 | 469,5 | 486,3 | 526,4 | 547,6 | 467,4 | 516,5 | 542,2 | 547,2 | мәгълүматлар юк |
| | | 5 | Идел буе федераль округы | 463,8 | 436,8 | 480,9 | 512,1 | 540,7 | 431,5 | 460,8 | 458,3 | 458,7 | мәгълүматлар юк |
| | | 6 | Татарстан Республикасы | 317,7 | 291,9 | 341,3 | 486,2 | 349,9 | 330,8 | 357,8 | 288,2 | 281,7 | 250,5 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Кан, кан ясагыч органнар авырулары һәм иммунитет механизмын җәлеп итә торган кайбер бозылулар | D50 – D89 | 7 | Россия Федерациясе | 907,4 | 929,0 | 877,0 | 867,4 | 823,9 | 688,0 | 761,9 | 872,8 | 902,9 | мәгълүматлар юк |
| | | 8 | Идел буе федераль округы | 983,8 | 910,9 | 912,9 | 908,1 | 857,4 | 800,6 | 882,9 | 1 101,7 | 1 127,4 | мәгълүматлар юк |
| | | 9 | Татарстан Республикасы | 1 340,4 | 1 175,8 | 1 211,7 | 1 332,8 | 1 416,9 | 1 376,4 | 1 433,6 | 1 586,0 | 1 599,2 | 1 348,4 |
| Нерв системасы авырулары | G00 – G98 | 10 | Россия Федерациясе | 3 937,5 | 3 864,3 | 3 795,6 | 3 781,1 | 3 807,5 | 3 187,0 | 3 549,5 | 3 769,7 | 3 855,9 | мәгълүматлар юк |
| | | 11 | Идел буе федераль округы | 4 772,6 | 4 462,6 | 4 274,6 | 4 143,4 | 4 145,3 | 3 426,0 | 3 886,1 | 4 465,8 | 4 669,0 | мәгълүматлар юк |
| | | 12 | Татарстан Республикасы | 4 390,6 | 3 536,4 | 3 514,8 | 4 233,0 | 4 414,7 | 4 023,1 | 4 728,0 | 4 752,8 | 4 861,4 | 4 397,1 |
| КӘСА – кан әйләнеше системасы авырулары; | I00 – I99 | 13 | Россия Федерациясе | 1 641,6 | 1 657,6 | 1 631,3 | 1 557,7 | 1 607,8 | 1 274,9 | 14 072 | 1 494,9 | 1 471,8 | мәгълүматлар юк |
| | | 14 | Идел буе федераль округы | 1 872,2 | 1 821,2 | 1 875,1 | 1 772,1 | 1 716,3 | 1 339,5 | 1 481,6 | 1 451,4 | 1 473,2 | мәгълүматлар юк |
| | | 15 | Татарстан Республикасы | 3 110,7 | 2 663,3 | 3 127,7 | 2 970,6 | 2 502,8 | 2 418,5 | 2 502,6 | 2 574,1 | 2 145,2 | 2 237,1 |
| Сулыш органнары авырулары | J00 – J98 | 16 | Россия Федерациясе | 67 304,8 | 68 856,4 | 69 589,4 | 69 858,7 | 68 619,5 | 67 148,8 | 73 463,1 | 49 285,3 | 83 775,8 | мәгълүматлар юк |
| | | 17 | Идел буе федераль округы | 75 434,5 | 76 111,8 | 76 363,6 | 76 448,9 | 74 538,2 | 72 778,7 | 82 051,6 | 86 632,1 | 94 821,9 | мәгълүматлар юк |
| | | 18 | Татарстан Республикасы | 61 138,0 | 59 929,6 | 63 527,0 | 65 608,8 | 67 861,2 | 69 602,6 | 78 095,1 | 72 619,4 | 78 337,7 | 79 381,5 |
| Сөяк-мускул системасы һәм тоташтыргыч | M00 – M99 | 19 | Россия Федерациясе | 5 888,3 | 5 726,3 | 5 649,9 | 5 621,2 | 5 603,0 | 4 319,4 | 4 913,7 | 5 241,4 | 5 250,4 | мәгълүматлар юк |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| тукыма авыру-лары | | 20 | Идел буе федераль округы | 6 461,0 | 6 117,9 | 5 920,2 | 5 840,1 | 5 860,7 | 4 355,6 | 4 640,8 | 5 042,5 | 5 138,1 | мәгълүматлар юк |
| | | 21 | Татарстан Республикасы | 7 511,1 | 6 302,0 | 7 300,0 | 7 099,0 | 6 429,4 | 5 198,6 | 5 536,2 | 6 650,1 | 5 130,6 | 5 359,6 |
| Тумыштан килгән аномалияләр (үсеш кимчелекләре), деформацияләр һәм хромосома бозылулары | Q00 – Q99 | 22 | Россия Федерациясе | 324,0 | 361,6 | 303,7 | 297,3 | 274,8 | 199,7 | 234,1 | 240,6 | 246,1 | мәгълүматлар юк |
| | | 23 | Идел буе федераль округы | 402,0 | 459,0 | 361,7 | 383,4 | 374,4 | 274,6 | 293,9 | 284,5 | 266,9 | мәгълүматлар юк |
| | | 24 | Татарстан Республикасы | 291,9 | 272,2 | 288,3 | 556,5 | 546,0 | 265,0 | 312,3 | 335,4 | 191,4 | 250,5 |
| Җәрәхәтләнүләр, агуланулар һәм тышкы сәбәпләрнең кайбер башка зыяннары | S00 – T98 | 25 | Россия Федерациясе | 17 322,5 | 17 473,7 | 1 7393,3 | 17 438,6 | 17 557,1 | 14 037,2 | 14 709,8 | 15 362,4 | 15 621,4 | мәгълүматлар юк |
| | | 26 | Идел буе федераль округы | 17 461,8 | 17 058,1 | 16 376,2 | 17 698,6 | 17 715,2 | 13 776,2 | 14 707,8 | 14 903,3 | 15 852,7 | мәгълүматлар юк |
| | | 27 | Татарстан Республикасы | 23 364,5 | 23 382,0 | 24 143,8 | 25 210,9 | 25 501,6 | 18 433,2 | 20 887,0 | 21 739,6 | 18 861,3 | 16 995,7 |

Республикада балансланган социаль-икътисадый система булдырылды:

урта һөнәри белем һәм югары белем бирүнең алга киткән системасы, кеше капиталын үстерү системасы буларак социаль өлкәнең югары потенциалы;

үсеш алган нефть-газ химиясе комплексы;

үсеш алган машина төзелеше комплексы;

чагыштырмача уңайлы табигать шартларында балансла агросәнәгать комплексы;

республика эчендә барлык төр җирлекләргә транспорт белән барып җиту мөмкинлеге.

Татарстан Республикасы, экология күзлегеннән караганда, чагыштырмача имин төбәк булып тора, 2024 елның көзге сезоны йомгаклары буенча «Яшел патруль» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Россия төбәкләре илкүләм экология рейтингында республика 83 урын арасыннан 55 нче урында тора.

Хәзерге җәмгыятьнең үзенчәлекле ягы, шул исәптән Татарстан Республикасында да, энергия чыгымнары киму, өстәмә физик активлык акрынлап киму. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматлары буенча, өлкәннәрнең һәм балаларның барлык авыруларының 80 проценты теге яки бу дәрәҗәдә туклану бозылу белән бәйле. Туклануның торышы, яшәү рәвешенең башка аспектлары белән беррәттән, йогышсыз авырулар формалашуга, төрле куркыныч факторлары йогынтысына һәм, нәтиҗәдә, тулаем алганда авырулар һәм үлем дәрәҗәсенә йогынты ясый.

Татарстан Республикасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, зурларга һәм балаларга диспансеризация үткәрүне, диспансер күзәтүен һәм профилактик медицина тикшерүен оештыруга, хроник йогышсыз авырулар һәм аларның үсеш рискы факторлары белән көрәшкә юнәлдерелгән профилактик чаралар комплексы гамәлгә ашырыла.

Сәламәт яшәү рәвешен булдыру мәсьәләләре Татарстан Республикасының ведомствоара комиссияләре утырышларында карап тикшерелә:

җәмәгать сәламәтлеге буенча төбәк советы;

Татарстан Республикасының хокук бозуларны профилактикалау буенча хөкүмәт комиссиясе;

Татарстан Республикасының хокук бозуларны профилактикалау буенча хөкүмәт комиссиясенең Татарстан Республикасында халык арасында алкоголь продукциясен, сыра, тәмәкене артык куллануны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен булдыру буенча эшче төркем;

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе;

Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссия;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия;

Татарстан Республикасында алкоголь һәм спиртлы продукция әйләнеше өлкәсендәге хәлне контрольдә тоту советы;

наркотикларга каршы өлкәдә проектлар гамәлгә ашыручы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс

нигезендә субсидияләр бирү комиссияләре (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы каршында);

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары, комиссияләре, эшче төркемнәре

;

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы мәгълүматлары

Төп чаралар Татарстан Республикасының дәүләт программалары кысаларында тормышка ашырыла:

паспорты

«Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» («Хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау эшчәнлеген оештыру», «Алкоголь продукциясен артык куллану масштабларын киметү һәм алкоголизмны профилактикалау», «Халык арасында наркоманияне профилактикалау» процесслы чаралар комплексы кысаларында);

«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» (Татарстан Республикасы яшьләрен патриотик тәрбияләү» төбәк проекты кысаларында).

2019 – 2024 елларда «Җәмәгать сәламәтлеген ныгыту» төбәк проектын гамәлгә ашыру йомгаклары буенча:

Татарстан Республикасының 45 муниципаль берәмлегендә халык арасында җәмәгать сәламәтлеген ныгыту буенча муниципаль программалар расланды һәм гамәлгә ашырыла;

түбәндәге эшчәнлек өлкәләрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре предприятиеләрендә һәм оешмаларында эшләүчеләрнең сәламәтлеген ныгыту турындагы корпоратив программаларны гамәлгә кертү буенча 85 килешү төзелде: сәламәтлек саклау (өч килешү), мәгариф (38 килешү), сәнәгать (11 килешү), транспорт (дүрт килешү), сәүдә (бер килешү), дәүләт идарәсе һәм муниципаль идарә (җиде килешү), көнкүреш предприятиеләре (бер килешү), башка (20 килешү).

Республикада профилактик чараларны гамәлгә ашыру федераль һәм төбәк норматив хокукый актлары нигезендә, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларында ел саен үткәрелә торган авыруларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен булдыру буенча тематик чаралар планнары кысаларында, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Медицина оешмаларында йогышсыз авыруларны профилактикалауны оештыру һәм гамәлгә ашыру һәм сәламәт яшәү рәвешен булдыру чараларын үткәрү тәртибен раслау турында» 2020 елның 29 октябрендәге 1177н номерлы боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Дүрт җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы үзәге (Казан, Әлмәт, Түбән Кама, Зеленодольск шәһәрләрендә), 20 сәламәтлек үзәге (15 – зурлар өчен һәм биш – балалар өчен), медицина профилактикасы буенча 29 бүлекчә һәм 63 кабинет, 66 сәламәт бала кабинеты, 15 зурлар өчен сәламәтлек үзәге үз эшчәнлеген республика халкы арасында аң-белем бирү эшен оештыру һәм үткәрү буенча җаваплы үзәк буларак гамәлгә ашыра (11 нче, 12 нче таблицалар).

Профилактик медицина ярдәме (профилактик медицина тикшерүләре, диспансеризация) оештыру максатларында 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан «Озак һәм актив тормыш» илкүләм

проектының «Һәркем өчен сәламәтлек» федераль проекты кысаларында республиканың биш муниципаль берәмлегендә медицина профилактикасы бүлекләре (кабинетлары) базасында зурлар өчен сәламәтлек үзәкләре оештыру билгеләнгән тәртиптә планлаштырыла
(1 нче рәс.).




1 нче рәс. Татарстан Республикасы территориясендә, 2030 елга кадәр яңа үзәкләр ачылуын исәпкә алып, зурлар өчен сәламәтлек үзәкләрен урнаштыру схема картасы

11 нче таблица

### Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре яктылыгында җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы үзәкләре, зурлар өчен сәламәтлек үзәкләре, медицина профилактикасы бүлекләре (кабинетлары)

| Т/с | Муниципаль район (шәһәр округы) исеме | Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы үзәге, берәмлек | Зурлар өчен сәламәтлек үзәге, берәмлек | | Медицина профилактикасы бүлеге (кабинеты), берәмлек |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | булган | ачырга планлаштырыла торган* | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | Әлмәт | 1 | 1 | - | ике медицина профилактикасы бүлеге, ике медицина профилактикасы кабинеты |
| 2. | Зеленодольск | 1 | 1 | - | бер медицина профилактикасы бүлеге, тугыз медицина профилактикасы кабинеты |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Түбән Кама | 1 | 1 | - | бер медицина профилактикасы бүлеге, бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 4. | Яр Чаллы шәһәре | - | 2 | - | җиде медицина профилактикасы кабинеты |
| 5. | Казан шәһәре | 1 | 8 | - | 11 медицина профилактикасы бүлеге, 17 медицина профилактикасы кабинеты |
| 6. | Әгерҗе | - | - | - | бер медицина профилактикасы бүлеге |
| 7. | Азнакай | - | - | - | бер медицина профилактикасы бүлеге |
| 8. | Аксубай | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 9. | Актаныш | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 10. | Алексеевск | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 11. | Әлки | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 12. | Арча | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 13. | Апас | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 14. | Әтнә | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 15. | Баулы | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 16. | Балтач | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 17. | Бөгелмә | - | 1 | - | бер медицина профилактикасы бүлеге |
| 18. | Буа | - | - | 1 (2028 ел) | бер медицина профилактикасы бүлеге |
| 19. | Югары Ослан | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 20. | Чүпрәле | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 21. | Зәй | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 22. | Алабуга | - | - | - | бер медицина профилактикасы бүлеге |
| 23. | Кайбыч | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 24. | Кама Тамагы | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 25. | Кукмара | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 26. | Лаеш | - | - | - | ике медицина профилактикасы кабинеты |
| 23. | Лениногорск | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 24. | Мамадыш | - | - | - | бер медицина профилактикасы бүлеге |
| 25. | Менделеевск | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 26. | Минзәлә | - | - | 1 (2029 ел) | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 27. | Мөслим | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 28. | Яңа Чишмә | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 29. | Нурлат | - | - | 1 (2030 ел) | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 30. | Питрәч | - | - | - | бер медицина профилактикасы бүлеге |
| 31. | Балык Бистәсе | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 32. | Саба | - | - | 1 (2027 ел) | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 33. | Сарман | - | - | - | ике медицина профилактикасы кабинеты |
| 34. | Спас | - | - | 1 (2027 ел) | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 35. | Тәтеш | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 36. | Тукай | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 37. | Теләче | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 38. | Чирмешән | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |
| 39. | Чистай | - | 1 | - | ике медицина профилактикасы кабинеты |
| 40. | Ютазы | - | - | - | бер медицина профилактикасы кабинеты |

12 нче таблица

## Татарстан Республикасының медицина профилактикасы хезмәте штатлары

| Медицина профилактикасы хезмәте штатлары | Табиблар | Урта медицина персоналы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| «Әлмәт җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы үзәге» ДАССУ | | |
| Штат ставкалары, берәмлек | 75,25 | 69 |
| Биләнгән ставкалар, берәмлек | 67 | 69 |
| Физик затлар, кеше | 43 | 41 |
| Зурлар өчен 20 сәламәтлек үзәге, балалар өчен биш сәламәтлек үзәге | | |
| Штат ставкалары, берәмлек | 53,25 | 117,5 |
| Биләнгән ставкалар, берәмлек | 35,75 | 97 |
| Физик затлар, кеше | 31 | 94 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 29 медицина профилактикасы бүлеге | | |
| Штат ставкалары, берәмлек | 63 | 262,5 |
| Биләнгән ставкалар, берәмлек | 47,25 | 223,75 |
| Физик затлар, кеше | 42 | 217 |
| 63 медицина профилактикасы кабинеты | | |
| Штат ставкалары, берәмлек | 14,5 | 41,75 |
| Биләнгән ставкалар, берәмлек | 6,85 | 31,5 |
| Физик затлар, кеше | 6 | 31 |

Балаларда һәм яшүсмерләрдә сәламәт яшәү рәвешен булдыру, йогышсыз авырулар, шул исәптән сулыш органнары авырулары үсеше рискы факторларын үз вакытында ачыклау максатларында, республикада балалар өчен сәламәтлек үзәкләренең (биш – Казан, Яр Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама шәһәрләрендә) республиканың мәгариф оешмалары белән үзара хезмәттәшлеге гамәлгә ашырыла.

Профилактика эшендә сәламәтлек саклау буенча махсуслаштырылган учреждениеләрнең медицина хезмәткәрләре, гомумдәвалау челтәре табиблары һәм урта медицина хезмәткәрләре актив роль уйный.

Төбәктә профилактика эшчәнлеге нигезендә ведомствоара хезмәттәшлек ята. Татарстан Республикасы халкының сәламәтлеген саклау һәм ныгыту буенча Татарстан Республикасында дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча ведомствоара эшне Җәмәгать сәламәтлеге буенча төбәк советы координацияли, аның составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 31 май, б-985 нче боерыгы белән расланды.

Татарстан Республикасында дәүләт сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре арасында – алкоголь продукциясен һәм тәмәке тартуны, иң беренче чиратта, балалар һәм үсмерләр арасында артык кулլануны профилактикалау мәсьәләләре.

Халык арасында, шул исәптән балалар һәм яшьләрдә тәмәке һәм никотинлы башка продукция куллануга каршы профилактик чаралар Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан түбәндәгеләр кысаларында гамәлгә ашырыла:

«Гражданнар сәламәтлеген әйләнә-тирәдәге тәмәке төтене зыяныннан, тәмәке тарту яки никотинлы продукция куллану зыяннарыннан саклау турында» 2013 елның 23 февралендәге 15-ФЗ номерлы Федераль законның «Балигъ булмаганнарга һәм балигъ булмаганнар тарафыннан тәмәке продукциясен яки никотинлы продукцияне, кальяннарны һәм никотинлы продукция куллану җайланмаларын сатуны тыю, балигъ булмаганнар тарафыннан тәмәке тартуны яки никотинлы продукция куллануны тыю, балаларны тәмәке тарту яки никотинлы продукция куллану процессына җәлеп итүне тыю» дигән 20 нче статья;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 30 апрелендәге б-1151 номерлы карары белән расланган 2035 елга кадәр чорга һәм алга таба перспективага Россия Федерациясендә тәмәке тартуга һәм никотинлы башка продукция куллануга каршы тору буенча дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планы һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Тәмәке тартуга һәм никотинлы башка продукция куллануга каршы тору чаралары планын

раслау турында» 2021 елның 8 июлендәге 1359 номерлы боерыгы;

2025 елга Татарстан Республикасында алкогольгә һәм тәмәкегә каршы өстәмә чаралар планы (Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Л.Н.Фазлыева тарафыннан расланды).

2025 елда «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник наркология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында «Гомуми эш. Алкоголизацияне һәм тәмәке тартуны киметү өчен» федераль проекты төбәк ресурс үзәге эшен дәвам итте.

«Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе белән эшчәнлекләре Татарстан Республикасы халкының сәламәт яшәү рәвешен булдыруга юнәлдерелгән коммерциягә карамаган волонтерлык оешмалары хезмәттәшлеге эше оештырылды (13 нче таблица).

13 нче таблица

Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру юнәлешендә эшләгән коммерциягә карамаган оешмалар белән хезмәттәшлек итү

| Т/с | Муниципаль берәмлекнең (административ округ яки районның) исеме | Коммерциягә карамаган оешмалар белән үзара хезмәттәшлек формасы | Коммерция булмаган оешмаларга ярдәм механизмнары |
|---|---|---|---|
| 1. | Казан шәһәре | социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга бирелгән, конкурс процедураларын уздырмыйча бүленә торган максатчан субсидия | дәүләт биреме |

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, тәмәке тарту, алкогольне артык куллану, рациональ булмаган туклану, физик активлыкның түбән булуы һәм стресс кебек хроник йогышсыз авырулар үсешенә йогынты ясый торган риск факторлары еш кына янәшә йөри һәм бер-берсен көчәйтә. Мәсәлән, сәламәт булмаган туклану һәм аз хәрәкәтләнә торган яшәү рәвеше симерүгә китерә, ә стресс артык ашау һәм алкоголь куллануга китерергә мөмкин. Бу үзара бәйләнеш һәр фактор белән аерым-аерым көрәшүне түгел, ә хроник йогышсыз авыруларны профилактикалауга комплекслы якын килү мөһимлеген ассызыклый (14 нче таблица).

14 нче таблица

**2025 елда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре яктылыгында хроник йогышсыз авырулар рискының үз-үзен тоту факторлары таралышы**

| Т/с | Муниципаль район (шәһәр округы) исеме | Хроник йогышсыз авырулар үсеше рискының үз-үзен тотышы факторлары, процент | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | никотинлы продукция куллану | алкогольне зарарлы куллану куркынычы | түбән физик активлык | дөрес тукланмау |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | Әгерҗе | 7,9 | 1,4 | 6,6 | 6,2 |
| 2. | Азнакай | 2,5 | 0,3 | 44,2 | 54,1 |
| 3. | Аксубай | 8,6 | 2,0 | 60,4 | 65,3 |
| 4. | Актаныш | 0,8 | 0,7 | 54,1 | 54,8 |
| 5. | Алексеевск | 2,4 | 1,1 | 19,6 | 19,4 |
| 6. | Әлки | 2,0 | 0,7 | 54,6 | 29,9 |
| 7. | Әлмәт | 5,4 | 3,2 | 39,1 | 45,2 |
| 8. | Апас | 5,4 | 2,4 | 32,6 | 25,5 |
| 9. | Арча | 2,3 | 0,3 | 3,7 | 5,1 |
| 10. | Әтнә | 7,3 | 1,3 | 16,1 | 19,6 |
| 11. | Баулы | 1,5 | 0,1 | 31,8 | 31,5 |
| 12. | Балтач | 1,2 | 0,9 | 40,1 | 47,9 |
| 13. | Бөгелмә | 0,8 | 0,2 | 4,2 | 3,8 |
| 14. | Буа | 3,4 | 0,4 | 63,3 | 62,8 |
| 15. | Югары Ослан | 1,7 | 0,6 | 49,1 | 34,0 |
| 16. | Биектау | 0,4 | 0,3 | 63,5 | 71,0 |
| 17. | Чүпрәле | 0,6 | 0,1 | 29,7 | 29,9 |
| 18. | Алабуга | 8,2 | 4,5 | 57,2 | 64,6 |
| 19. | Зәй | 4,4 | 1,9 | 40,1 | 39,7 |
| 20. | Зеленодольск | 3,9 | 1,2 | 55,1 | 51,9 |
| 21. | Кайбыч | 1,3 | 0,5 | 34,2 | 21,8 |
| 22. | Кама Тамагы | 15,1 | 3,0 | 17,0 | 12,0 |
| 23. | Кукмара | 0,9 | 1,0 | 16,7 | 17,1 |
| 24. | Лаеш | 1,7 | 0,3 | 19,6 | 17,8 |
| 25. | Лениногорск | 2,9 | 0,6 | 79,9 | 76,9 |
| 26. | Мамадыш | 10,1 | 1,6 | 20,4 | 14,8 |
| 27. | Менделеевск | 2,6 | 0,4 | 22 | 22,2 |
| 28. | Минзәлә | 2,8 | 5 % | 17,5 | 39,9 |
| 29. | Мөслим | 4,8 | 0,4 | 59,4 | 64,5 |
| 30. | Түбән Кама | 5,8 | 1,9 | 65,9 | 45,2 |
| 31. | Яңа Чишмә | 4,4 | 0,8 | 68,2 | 67,1 |
| 32. | Нурлат | 1,7 | 0,1 | 45,9 | 56,1 |
| 33. | Питрәч | 10,3 | 3,0 | 57,0 | 48,5 |
| 34. | Балык Бистәсе | 8,5 | 0,6 | 53,6 | 36,6 |
| 35. | Саба | 9,2 | 2,0 | 29,8 | 43,6 |
| 36. | Сарман | 0,7 | 0,1 | 53,8 | 51,5 |
| 37. | Спас | 8,5 | 0,6 | 60,4 | 55,7 |
| 38. | Тәтеш | 3,6 | 0,7 | 48,4 | 46,9 |
| 39. | Тукай | 1,4 | 0,1 | 49,2 | 49,7 |
| 40. | Теләче | 4,7 | 0,7 | 40,9 | 69,6 |
| 41. | Чирмешән | 5,9 | 0,6 | 35,9 | 55,4 |
| 42. | Чистай | 1,5 | 0,2 | 67,1 | 65,4 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 43. | Ютазы | 0,5 | 0,5 | 64,2 | 50,9 |
| 44. | Яр Чаллы шәһәре | 2,3 | 0,1 | 33,1 | 34,9 |
| 45. | Казан шәһәре | 3,5 | 1,5 | 36,0 | 40,7 |
| | Татарстан Республикасы буенча барлыгы | 3,7 | 1,2 | 35,6 | 37,4 |

Гигиеник белем бирү һәм тәрбияләү, балалар арасында йогышлы һәм йогышсыз авыруларны профилактикалау, шулай ук ата-аналарны һәм йөкле хатын-кызларны үзүзеңне тоту буенча төп кагыйдәләргә өйрәтү, шул исәптән зарарлы гадәтләрдән баш тарту, социаль шартларга җайлашкан сәламәт бала тәрбияләү максатларында республика балалар поликлиникаларында (консультацияләрендә) сәламәт бала кабинетлары эше оештырылды. Сәламәт бала кабинетлары базасында йөкле хатыннар, аналар һәм әтиләр мәктәпләре эшли (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Сәламәт бала кабинетлары эшен оештыру турында» 2006 елның 6 июлендәге 706 номерлы боерыгы).

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник наркология диспансеры» ДАССУ базасында тәмәке тартудан баш тартуда ярдәм күрсәтү буенча «кайнар линия» эшли. «Кайнар линия» телефоны буенча табиблар – психиатр-наркологлар тәмәке тартудан баш тартуның иң нәтиҗәле ысуллары буенча консультацияләр бирәләр, төрле авырулары булган пациентларга, сәламәтлеккә бәйле проблемаларны исәпкә алып, тәмәке тартудан баш тартуга ничек яхшырак әзерләнергә кирәклеге турында индивидуаль киңәшләр бирәләр.

«Кайнар линия» турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Республика клиник наркология диспансеры» ДАССУнең рәсми сайтында урнаштырылды: http://rnd-kazan.ru/ (телефон номеры: 8(843)272-19-82, эш режим: эш көннәрендә 9 сәгать 00 минуттан 16 сәгать 00 минутка кадәр).

Гомуми белем, урта һөнәри белем һәм югары белем алучылар арасында тәмәкегә каршы мәгълүмат-аң-белем бирү эшен үткәрү өлешендә сәламәтлек саклау һәм мәгариф оешмалары белгечләренең үзара хезмәттәшлеге гамәлгә ашырыла (тематик чаралар, семинарлар, әңгәмәләр, тематик мәгълүмати материал тарату).

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән килешү нигезендә республиканың гомуми белем бирү оешмаларында медицина хезмәткәрләре катнашында төрле медицина-профилактика темаларына даими нигездә ата-аналар җыелышлары уздырыла. Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында түләүсез трансляцияләү өчен тематик видеоматериал бирелә.

Республиканың наркология хезмәте белгечләре, республика җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы үзәкләре белән берлектә, мәктәпләр җитәкчеләре, психологлары, социаль педагоглары һәм медицина хезмәткәрләре өчен «Мәгариф һәм сәламәтлек» темасына семинар-киңәшмәләрдә катнаша.

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник наркология диспансеры» ДАССУ табиблары – психиатр-наркологлары полиция бүлекләренең балигъ булмаганнар эшләре бүлекчәләрендә балигъ булмаганнарны кабул итәләр, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау ко-

миссияләре утырышларында һәм ведомствоара социаль-тернәкләндерү консилиумнары эшендә катнашалар, балигъ булмаганнарның сукбайлыгын, күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү буенча профилактика системасының башка органнары һәм учреждениеләре белән актив хезмәттәшлек итәләр.

Балалар һәм яшүсмерләр арасында алкоголь куллануны иртә ачыклау максатларында шулай ук Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләре һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча муниципаль комиссияләр белән хезмәттәшлек алып барыла.

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник наркология диспансеры» ДАССУдә балалар наркологиясе һәм наркологик тайпылышларны профилактикалау бүлеге ачылды, ул, беренче чиратта, балигъ булмаганнар арасында профилактикалау, иртә ачыклау һәм диспансер күзәтүе өлкәсендә эшләүче диспансер бүлекчәләрен берләштерә

2015 елдан Татарстан Республикасында авыр тормыш хәленә эләккән, балигъ булмаган балалары булган һәм ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителү куркынычы янаган йә ата-ана хокуклары чикләнгән алкогольле пациентларны реабилитацияләү буенча комплекслы программа кертелде. Программага «Аеклык ноктасы» проекты» исеме бирелде.

«Аеклык ноктасы» проектын» гамәлгә ашыру кысаларында гражданнарны дәвалануга һәм реабилитацияләүгә мотивацияләү буенча чаралар үткәрелә, индивидуаль, гаилә һәм үз-үзеңне тоту психотерапиясе элементлары кулланыла, пациентка һәм аның гаиләсенә социаль ярдәм күрсәтеп торыла. «Аеклык ноктасы» проектында» катнашучыларны кабул итү һәм карау, дәвалау процессын оештыру, аларга карата психотерапия һәм реабилитация эшләрен уздыру Россия Федерациясе гражданнарына Татарстан Республикасы территориясендә түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы, «психиатрия-наркология» профиле буенча махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүнең клиник тәкъдимнамәләре һәм стандартлары кысаларында тәэмин ителә.

Ел саен республикада наркотик һәм психотроп матдәләрне законсыз куллануны иртә ачыклау максатларында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә гомуми белем бирү оешмаларында, һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында укучыларга профилактик медицина тикшерүләре, хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарга тестлар үткәрелә.

Халыкны физик активлыкка җәлеп итү максатларында (спорт һәм физик культура белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру, спорт чараларын, ял итү зоналарын оештыру, актив яшәү рәвешен пропагандалау) Татарстан Республикасында махсуслаштырылган хезмәт – Казан шәһәренең «Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» ДАССУнең спорт медицинасы бүлекчәләре, Әлмәт, Түбән Кама, Зеленодольск шәһәрләрендә җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы үзәкләре һәм Яр Чаллы шәһәренең «Табиб-физкультура диспансеры» ДАССУ эшчәнлеге башкарыла.

Югарыда күрсәтеп үтелгән мәсьәлә буенча Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче затларга

(шул исәптән физкультура чараларын һәм спорт чараларын әзерләгәндә һәм уздырганда) медицина ярдәме күрсәтүне оештыру тәртибен (оешмаларда спорт әзерлеге узарга, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнергә һәм (яисә) «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) бөтенроссия физкультура-спорт комплексы сынаулары (тестлары) нормативларын үтәргә теләүче затларга медицина тикшерүе тәртибен һәм физкультура һәм спорт чараларында катнашырга рөхсәт итү турында медицина бәяләмәләре формаларын кертеп) раслау турында» 2020 елның 23 октябрендәге 1144н номерлы боерыгы нигезендә кирәкле эш үткәрелә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Л.Ф. Фазлыева тарафыннан расланган 2026 елга кадәр чорга Татарстан Республикасында спорт медицинасын үстерү стратегиясе гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче затларга «дәвалау физкультурасы һәм спорт медицинасы» профиле буенча беренчел махсуслаштырылган медицина ярдәмен оештыру максатларында гражданнарны маршрутлаштыру тәртибе билгеләнде, шул исәптән түбәндәгеләр расланды:

2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын гамәлгә ашыруда катнашучы, Татарстан Республикасында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче затларга «дәвалау физкультурасы һәм спорт медицинасы» профиле буенча беренчел махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүче Татарстан Республикасы медицина оешмалары исемлеге;

«Татарстан Республикасында «дәвалау физкультурасы һәм спорт медицинасы» профиле буенча беренчел махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтү өчен физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче затларны маршрутлаштыру схемасы.

Халыкка диспансеризация һәм профилактик медицина тикшерүе үткәрү барышында процесс белән идарә итү системасы гамәлгә ашырыла: фаразлау, планлаштыру, мониторинг, методологик ярдәм күрсәтү, контроль элементлары, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары һәм эш бирүчеләр җаваплылыгы һәм ярдәме күздә тотыла торган Татарстан Республикасы халкына диспансеризация үткәрүне тәэмин итү турында 2014 ел, 7 август, б-1520 нче боерыгын исәпкә алып, федераль һәм республика ведомстволары белән үзара хезмәттәшлек итүе кертелде һәм файдаланылды.

Билгеләнгән чаралар арасында:

1. Балалар арасында үткәрелә:

2007 елдан башлап – мәгариф оешмаларында, социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында һәм медицина оешмаларының стационар шартларында булган, авыр тормыш хәлендә калган ятим балаларга һәм балаларга диспансеризация үткәрү;

2013 елдан башлап – ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, шул исәптән уллыкка (кызлыкка) алынган, опекага (попечительлеккә) алынган, тәрбия бирә торган гаиләгә яисә патронаж гаиләгә алынган балаларга диспансеризация үткәрү;

2016 елдан башлап – ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалар күзәтүенә урнаштырыла торган ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга медицина тикшерүен оештыру.

Эш ата-аналарның, опекуннарның һәм аларга тиңләштерелгән затларның язма ризалыгы белән башкарыла. Участок-территория принцибы буенча беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче 61 медицина оешмасы катнаша;

2013 елдан башлап – балигъ булмаганнарның профилактик медицина тикшерүләрен үткәрү.

2. Зурлар арасында үткәрелә:

2013 елдан башлап – өлкәннәрнең аерым төркемнәренең профилактик медицина тикшерүен һәм диспансеризациясен оештыру, шул исәптән 2021 елның 1 июленнән – яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) белән авырган гражданнарга тирәнтен диспансеризациясен үткәрү (терелгәннән соң 60 көн узгач уздырыла);

2024 елдан башлап – репродуктив яшьтәге (18 – 49 яшь) хатын-кызларның һәм ир-атларның репродуктив сәламәтлеген бәяләүгә юнәлдерелгән диспансеризация.

Авыл җирлегендә диспансеризация үткәргәндә, белгечләрнең күчмә эш формалары кулланыла, шул исәптән мобиль медицина бригадалары ярдәмендә башкарыла.

Диспансеризацияне даими рәвештә узып тору инвалидлыкның һәм үлемнең төп сәбәбе булып торган түбәндәге аеруча куркыныч авырулар үсешен шактый дәрәҗәдә киметергә һәм аларны дәвалау нәтиҗәлерәк булган вакытта иртәрәк ачыкларга мөмкинлек бирә: йөрәк-кан тамырлары системасы, яман шешләр (колоректаль яман шеш, аналык муены һәм күкрәк бизе яман шешләре), шикәр диабе һәм хроник үпкә авырулары.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан халык арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, авыруларны, шул исәптән социаль әһәмиятле авыруларны профилактикалау буенча, наркоманиягә, алкоголизмга, тәмәке тартуга каршы тору буенча (матбугат конференцияләре, максатчан тематик тапшырулар, телесюжетлар, радиочыгышлар, матбугатта басмалар) Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән даими нигездә хезмәттәшлек итә.

Халык арасында аң-белем бирү чараларын үткәргәндә республика медицина хезмәткәрләре Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының Сезнең сәламәтлегегез турында порталыннан (https://www.takzdorovo.ru/) тематик мәгълүмат материалларын, шулай ук Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм «Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәгенең» «ВКонтакте», «Одноклассники» һәм «Telegram» социаль челтәрләрен актив куллана.

Төбәк программасы кысаларында түбәндәгеләр каралды:

зурлар өчен 15 сәламәтлек үзәген хроник йогышсыз авырулар үсеше рискы факторларын ачыклау һәм коррекцияләү җайланмалары белән җиһазландыру (җиһазландырып бетерү);

медицина оешмаларында, шул исәптән ерак урнашкан торак пунктларда медицина профилактикасы бүлекчәләре (кабинетлары) базасында зурлар өчен биш сәламәтлек үзәге оештыру;

сәламәт яшәү рәвеше алып бару һәм хроник йогышсыз авыруларны профилактикалау буенча корпоратив һәм муниципаль программаларны яңарту;

сәламәт яшәү рәвеше алып бару буенча индивидуаль программалар булдырып, шул исәптән эшнең күчмә ысулларын кулланып, хроник йогышсыз авырулар үсеше

куркынычы факторларына ия гражданнарга диспансер күзәтүен оештыру һәм үткәрү;

Татарстан Республикасының зурлар өчен сәламәтлек үзәкләре тарафыннан эш урынында эшләүче гражданнарны тикшерүне, шулай ук авырулар үсешендә ачыкланган рискларга ия затларга диспансер күзәтүен оештыру.

Татарстан Республикасында хроник йогышсыз авыруларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен булдыру мәсьәләләре буенча эшне регламентлаштыра торган норматив хокукый актлар:

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Медицина оешмаларында йогышсыз авыруларны профилактикалауны оештыру һәм гамәлгә ашыру, сәламәт яшәү рәвешен булдыру чараларын үткәрү тәртибен раслау турында» 2020 елның 29 октябрендәге 1177н номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия Федерациясе субъектында беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтелә торган медицина оешмалары структурасында булган зурлар өчен сәламәтлек саклау үзәкләрен җиһазландыру (җиһазландырып бетерү), шулай ук район үзәк хастаханәләрендә, район хастаханәләрендә, шул исәптән ерак урнашкан торак пунктларда медицина профилактикасы бүлекчәләре (кабинетлары) базасында яңа оештырылган зурлар өчен сәламәтлек үзәкләрен җиһазландыру өчен хроник йогышсыз авырулар үсеше рискын ачыклау һәм коррекцияләү җайланмалары исемлеген раслау турында» 2025 елның, 11 апрелендәге 183н номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссия эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре турында» 2007 елның 25 декабрендәге ПУ-698 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы хөкүмәт комиссиясе турында» 2010 елның 9 гыйнварындагы ПУ-1 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында алкогольле һәм спиртлы продукция әйләнеше өлкәсендә хәлне контрольдә тоту советын оештыру турында» 2010 елның 3 февралендәге ПУ-41 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составын раслау турында» 2005 елның 6 сентябрендәге 438 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында «2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2012 ел, 24 сентябрь, 798 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын

раслау турында» 2019 ел, 5 март, 158 нче карары;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Татарстан Республикасы медицина оешмаларында йогышсыз авыруларны профилактикалауны оештыру һәм гамәлгә ашыру һәм сәламәт яшәү рәвешен булдыру чараларын үткәрү тәртибе турында» 2020 елның 22 декабрендәге 2306 номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Зурлар яшендәге халыкка никотинга бәйлелектән арыну өчен медицина ярдәме күрсәтүне оештыру турында» 2021 елның 15 июнендәге 1181 номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Тәмәке тартуга һәм башка никотинлы продукция куллануга каршы тору чаралары планын раслау турында» 2021 елның 8 июлендәге 1359 номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Татарстан Республикасының зурлар яшендәге халкы өчен сәламәтлек үзәкләренең җаваплылык зоналары турында» 2025 елның 9 июнендәге 1220 номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «2025 елда сәламәт яшәү рәвеше алып бару буенча индивидуаль программалар булдырып, шул исәптән эшнең күчмә ысулларын кулланып, хроник йогышсыз авырулар үсеше куркынычы факторларына ия гражданнарга диспансер күзәтүен оештыру һәм уздыру өчен гражданнарның план саны бүленешен раслау турында» 2025 елның 17 июлендәге 536 номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «2025 елда Татарстан Республикасының зурлар яшендәге халкы өчен сәламәтлек үзәкләре тарафыннан эш урынында тикшерү оештыру һәм уздыру, шулай ук авырулар үсеше рискының ачыкланган факторларына ия затларны эш урынында диспансер күзәтү өчен эшләүче гражданнарның план саны бүленешен раслау турында» 2025 елның 30 июлендәге 1669 номерлы боерыгы.

## Нәтиҗәләр

Татарстан Республикасы гражданнары арасында йогышсыз, шул исәптән йөрәк-кан тамырлары һәм онкология авырулары кебек үлемгә китерә торган төп сәбәпләрдән булган авырулар үсеше куркынычы факторларының югары дәрәҗәдә таралуы билгеләнә. Гражданнарның үз сәламәтлеген саклау өчен мотивациясе һәм җаваплылыгы җитәрлек дәрәҗәдә булмавы саклана.

Шуңа бәйле рәвештә сәламәтлекне саклау һәм ныгыту мәсьәләләре буенча халыкның мәгълүматлылыгын арттыруга, диспансеризация, профилактик медицина тикшерүләре узарга һәм диспансерлаштыруга бирелгәнлеккә, хроник йогышсыз авырулар куркынычы факторларын иртә ачыклауга юнәлдерелгән өстәмә чаралар кирәк.

Сәламәтлек саклау өлкәсендә профилактика өстенлеген гамәлгә ашыру дәүләт һәм башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан сәламәт яшәү рәвешен булдыруга, шулай ук йогышсыз авыруларны һәм аларны үстерү куркынычы факторларын үз вакытында ачыклауга юнәлдерелгән махсус программаларны алга таба эшләү һәм гамәлгә ашыру юлы белән тәэмин ителергә тиеш.

Гражданнарда, шул исәптән балалар һәм яшүсмерләрдә сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга гражданнарда аларның сәламәтлеге өчен куркыныч факторлар турында мәгълүматлылыгын арттыруга, сәламәт яшәү рәвешен алып баруга мотивация булдыруга юнәлдерелгән чаралар сизелерлек ярдәм итәргә тиеш.

Тәмәке тарту һәм алкоголизм проблемалары аерым игътибарга лаек.

Халыкның сәламәт яшәү рәвешен алып баруга мотивациясен арттыру процессы халыкка йогышсыз авырулар һәм бәйлелекләр куркынычы факторлары турында мәгълүмат бирүдә, сәламәт яшәү рәвеше алып баруга мотивация системасын булдыруда һәм моның өчен тиешле шартлар тәэмин итүдә, шулай ук барлык бу процессларны тикшереп торуда катнашучы республика башкарма хакимият органнарын, иҗтимагый оешмаларны әлеге программаны гамәлгә ашыруга җәлеп итеп, ведомствоара күп баскычлы, шул исәптән мониторинг үткәреп, хезмәттәшлек итүдән гыйбарәт.

Профилактик чаралар йөрәк-кан тамырлары һәм онкология авыруларына каршы көрәштә, барыннан да элек, эшкә сәләтле яшьтәге гражданнар арасында төп чара булырга тиеш. Иң мөһим ресурсларның берсе – мәгълүмати кампанияләр уздыру.

Төбәк программасы «Озак һәм актив тормыш» илкүләм проектының «һәркем өчен сәламәтлек» федераль проекты чараларын гамәлгә ашыру кысаларында формалаштырылды.

Төбәк программасының күрсәткечләре 15 нче таблицада китерелде.

15 нче таблица

2025 – 2030 елларга төбәк программасының күрсәткечләре

| Т/с | Күрсәткеч исеме | База күрсәткечләре (2023 елның 31 декабренә) | Төбәк программасын гамәлгә ашыру еллары буенча күрсәткечләр | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 год |
| 1. | Сәламәт яшәү рәвеше алып баручы гражданнар өлеше, процент | 13,7 | 15,9 | 16,6 | 17,4 | 18,1 | 19,2 | 20,5 |
| 2. | Сәламәтлек үзәкләрендә тирәнтен профилактик консультация узган, профилактик караулар һәм диспансеризация нәтиҗәсендә ачыкланган риск факторларына ия булган гражданнар өлеше, процент | 0,0 | - | - | - | - | - | - |
| 3. | Халыкның җан башына алкоголь продукциясен куллану, этанол литрларында | 8,49 | 8,29 | 8,2 | 8,12 | 8,03 | 7,94 | 7,85 |
| 4. | 18 яшьтә һәм аннан зуррак кешеләр арасында тәмәке тартуның таралуы, процент | 14,83 | 14,49 | 14,14 | 13,79 | 13,45 | 13,10 | 12,76 |

## Төбәк программасының максаты һәм бурычлары

Төбәк программасының максаты – сәламәт яшәү рәвеше алып баручы гражданнар өлешен 2025 елда 15,9 процenttан 2030 елга 20,5 процентка кадәр арттыру.

Төбәк программасының бурычлары:

халыкның сәламәт яшәү рәвеше турында хәбәрдарлыгын арттыру (сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыруга юнәлдерелгән мәгълүмати кампанияләр, дөрес туклану, начар гадәтләрдән баш тарту һәм даими физик активлыкны кертеп);

авыруларны (бигрәк тә, хроник йогышсыз авырулар, шул исәптән йөрәк-кан тамырлары, сулыш органнары авырулары, онкологик авырулар, шикәр диабеты) профилактикалау;

профилактик медицина ярдәмен билгеләнгән тәртиптә (профилактик медицина тикшерүләре) диспансеризация, зурлар өчен сәламәтлек үзәкләре эшен) оештыру;

халык арасында рисклар факторларын (шул исәптән тәмәке тарту, алкоголь һәм наркотик матдәләр куллану, дөрес тукланмау, физик активлык җитәрлек дәрәҗәдә булмау) киметү.

## Төбәк программасын гамәлгә ашыру сроклары

Төбәк программасын гамәлгә ашыру сроклары: 2025 – 2030 еллар.

Төбәк программасы чаралары планы 16 нчы таблицада күрсәтелде.

16 нчы таблица

## Төбәк программасы чаралары планы

| Т/с | Чара исеме | Аккредитация башлану датасы | Аккредитация төгәлләнү датасы | Җаваплы башкаручы | Нәтиҗә характеристикасы, чараларны үтәү критерийлары |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| I. Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру чараларын оештыру. Сәламәт яшәү рәвеше алып баручы гражданнар өлешен арттыру, | | | | | |
| 1.1. | «Һәркем өчен сәламәтлек» федераль проекты кысаларында сәламәт яшәү рәвеше мәсьәләләре буенча федераль һәм республика норматив хокукый актларын һәм методик документларын кертү | 01.01.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының территориаль идарәләре җитәкчеләре, Татарстан Республикасы медицина оешмаларының баш табиблары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | сәламәт яшәү рәвеше алып баручы гражданнар өлешен арттыруны тәэмин итү;<br>2025 елда – 15,9 процент;<br>2026 елда – 16,6 процент;<br>2027 елда – 17,4 процент;<br>2028 елда – 18,1 процент;<br>2029 елда – 19,2 процент;<br>2030 елда – 20,5 процент |
| 1.2. | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Л.Р.Фазлыева җитәкчелегендә җәмәгать сәламәтлеге буенча төбәк советы эшчәнлеген оештыруда катнашу | 01.01.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасының республика башкарма хакимият органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының территориаль сәламәтлек саклау идарәләре җитәкчеләре;<br>Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмасының исеме | Җәмәгать сәламәтлеген ныгыту, ведомствоара хезмәттәшлек нәтиҗәлелеген арттыру чаралары комплексын гамәлгә ашыруны тәэмин итү |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 1.3. | «Һәркем өчен сәламәтлек» федераль проекты кысаларында җәмәгать сәламәтлеген ныгыту буенча яңартылган программаларны эшләү һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә гамәлгә кертү | 01.03.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» ДАССУ, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының территориаль сәламәтлек саклау идарәләре җитәкчеләре, Татарстан Республикасы медицина оешмаларының баш табиблары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | Җәмәгать сәламәтлеген ныгыту буенча яңартылган муниципаль программаларны гамәлгә ашыру:<br>2025 елда – Татарстан Республикасының алты муниципаль берәмлегендә;<br>2026 елда – Татарстан Республикасының 12 муниципаль берәмлегендә;<br>2027 елда – Татарстан Республикасының 18 муниципаль берәмлегендә;<br>2028 елда – Татарстан Республикасының 25 муниципаль берәмлегендә;<br>2029 елда – Татарстан Республикасының 40 муниципаль берәмлегендә;<br>2030 елда – Татарстан Республикасының 45 муниципаль берәмлегендә |
| 1.4. | Зурлар өчен сәламәтлек үзәкләрен хроник йогышсыз авырулар үсеше куркынычын ачыклау һәм коррекцияләү җайланмалары белән җиһазландыру | 01.03.2025 | 31.12.2027 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» ДАССУ | 2025 елда – зурлар өчен тугыз сәламәтлек үзәге;<br>2026 елда – зурлар өчен өч сәламәтлек үзәге;<br>2027 елда – зурлар өчен өч сәламәтлек үзәге |
| 1.5. | Биш район үзәк хастаханәсенең медицина профилактикасы бүлекчәләре (кабинетлары) базасында зурлар өчен сәламәтлек үзәкләрен оештыру | 01.03.2027 | 31.12.2028 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» ДАССУ, үзәк район хастаханәләренең баш табиблары | 2027 елда – зурлар өчен ике сәламәтлек үзәге;<br>2028 елда – зурлар өчен бер сәламәтлек үзәге;<br>2029 елда – зурлар өчен бер сәламәтлек үзәге;<br>2030 елда – зурлар өчен бер сәламәтлек үзәге |
| 1.6. | Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртипләр нигезендә зурлар һәм | 01.03.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Җәмәгать сәламәтлеге һәм меди- | Зурлар һәм балалар арасында хроник йогышсыз авыруларны һәм аларның үсеш куркынычы факторларын иртә ачыклау, хроник йогышсыз авырулар куркынычы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | балалар өчен профилактик медицина тикшерүләрен һәм диспансеризация оештыру һәм үткәрү | | | цина профилактикасы буенча республика үзәге» ДАССУ, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының терапия, гомуми табиб практикасы һәм медицина профилактикасы буенча штаттан тыш баш белгечләре, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының территориаль сәламәтлек саклау идарәләре җитәкчеләре<br>Татарстан Республикасы медицина оешмаларының, шул исәптән зурлар өчен 15 сәламәтлек үзәгенең баш табиблары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | факторларын төзәтү |
| 1.7. | сәламәт яшәү рәвеше алып бару буенча индивидуаль программалар булдырып, шул исәптән эшнең күчмә ысулларын кулланып, хроник йогышсыз авырулар үсеше куркынычы факторларына ия гражданнарга диспансер күзәтүен оештыру һәм үткәрү | 01.03.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» ДАССУ, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының территориаль сәламәтлек саклау идарәләре җитәкчеләре, Татарстан Республикасы медицина оешмаларының, шул исәптән зурлар өчен 15 сәламәтлек үзәгенең баш табиблары, Татарстан Республикасы | 2025 елда – 63 269 кеше;<br>2026 елда – 84 358 кеше;<br>2027 елда – 126 537 кеше;<br>2028 елда – 168 716 кеше;<br>2029 елда – 210 895 кеше;<br>2030 елда – 253 074 кеше |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | |
| 1.8. | Хроник йогышсыз авыруларның таралышын, аларның үсеш куркынычы факторларын, халыкның төрле төркемнәренең сәламәтлекне саклау һәм ныгыту мәсьәләләре буенча мәгълүматлылык дәрәҗәсен мониторинглауга юнәлдерелгән чаралар оештыру (статистик хисап формаларын анализлау, эпидемиологик тикшеренүләр, социологик сораштырулар үткәрү) | 01.03.2025 | 31.12.2030 | «Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» ДАССУ, «Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» ДАССУ, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | Хроник йогышсыз авыруларның таралышын, аларның үсеш куркынычы факторларын мониторинглау |
| 1.9. | Халыкның төрле максатчан төркемнәре өчен гражданнарны сәламәт яшәү рәвешенә (сәламәт туклануны, хәрәкәт активлыгын һәм зарарлы гадәтләрдән баш тартуны кертеп) мотивацияләүгә юнәлдерелгән мәгълүмати-коммуникацион кампанияләр оештыру | 01.03.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» ДАССУ, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча), Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының территориаль сәламәтлек саклау идарәләре җитәкчеләре, Татарстан Республикасы медицина оешмаларының, шул исәптән зурлар өчен 15 сәламәтлек үзәгенең баш табиблары | Татарстан Республикасы халкын сәламәт яшәү рәвеше алып баруга мотивацияләү, хроник йогышсыз авыруларны һәм аларны үстерү куркынычы факторларын профилактикалау чараларын гамәлгә ашыру |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 1.10. | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауның актуаль мәсьәләләре буенча Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә телевизион һәм радиотапшырулар әзерләү һәм эфирга чыгару | 01.03.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» ДАССУ, Татарстан Республикасы медицина оешмаларының баш табиблары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | Татарстан Республикасы халкын сәламәт яшәү рәвеше алып баруга мотивацияләү, хроник йогышсыз авыруларны һәм аларны үстерү куркынычы факторларын профилактикалау чараларын гамәлгә ашыру |
| 1.11. | Сәламәт яшәү рәвешен булдыру, шул исәптән сәламәт туклану һәм физик активлык, зарарлы гадәтләрдән баш тарту мәсьәләләре буенча халык өчен басма продукцияне (плакатлар, белешмәләр, листовкалар, буклетлар, флайерлар) тиражлау һәм тарату | 01.03.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» ДАССУ, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының территориаль сәламәтлек саклау идарәләре җитәкчеләре, Татарстан Республикасы медицина оешмаларының, шул исәптән зурлар өчен 15 сәламәтлек үзәгенең баш табиблары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | Татарстан Республикасы халкын сәламәт яшәү рәвеше алып баруга мотивацияләү, хроник йогышсыз авыруларны һәм аларны үстерү куркынычы факторларын профилактикалау чараларын гамәлгә ашыру |
| 1.12. | Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре буенча социаль рекламаны биналар эчендәге мәгълүмат таблола- | 01.03.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» ДАССУ, Татарстан | Татарстан Республикасы халкын сәламәт яшәү рәвеше алып баруга мотивацияләү, хроник йогышсыз авыруларны һәм аларны үстерү куркынычы факторларын профилактикалау чараларын гамәлгә |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | рында, ведомство плазмаларында трансляцияләү | | | Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының территориаль сәламәтлек саклау идарәләре җитәкчеләре, Татарстан Республикасы медицина оешмаларының баш табиблары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | ашыру |
| 1.13. | Сәламәт яшәү рәвеше буенча медицина хезмәткәрләре, балалар һәм яшьләр арасында смотр-конкурслар оештыру һәм үткәрү | 01.03.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Җәмгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» ДАССУ, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының территориаль сәламәтлек саклау идарәләре җитәкчеләре, Татарстан Республикасы медицина оешмаларының баш табиблары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | Татарстан Республикасы халкын сәламәт яшәү рәвеше алып баруга мотивацияләү, хроник йогышсыз авыруларны һәм аларны үстерү куркынычы факторларын профилактикалау чараларын гамәлгә ашыру |
| 1.14. | Өлкәннәр өчен сәламәтлек мәктәпләрен, скандинавия йөреше клубларын, когнитив сәламәтлек программаларын оештыруны да кертеп, актив озак яшәү программаларын үстерү | 01.03.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, дүрт җәмгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы үзәге, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының гериатрия, гомуми табиб практикасы һәм медицина профилактикасы буенча | Татарстан Республикасы халкын сәламәт яшәү рәвеше алып баруга мотивацияләү, хроник йогышсыз авыруларны һәм аларны үстерү куркынычы факторларын профилактикалау чараларын гамәлгә ашыру |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | штаттан тыш баш белгечләре, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының территориаль сәламәтлек саклау идарәләре җитәкчеләре, Татарстан Республикасы медицина оешмаларының баш табиблары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | |
| 1.15. | Үзгәрешләр кертү мөмкинлеге белән ел саен төбәк программасының нәтиҗәлелегенә анализ ясау | 01.03.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, дүрт җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы үзәге, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының гериатрия, гомуми табиб практикасы һәм медицина профилактикасы буенча штаттан тыш баш белгечләре, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының территориаль сәламәтлек саклау идарәләре җитәкчеләре, Татарстан Республикасы медицина оешмаларының баш табиблары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | Татарстан Республикасы халкын сәламәт яшәү рәвеше алып баруга мотивацияләү, хроник йогышсыз авыруларны һәм аларны үстерү куркынычы факторларын профилактикалау чараларын гамәлгә ашыру |
| II. Җәмәгать берләшмәләрен җәлеп итеп, хезмәт коллективларында (предприятиеләрдә, оешмаларда) сәламәт яшәү рәвеше өчен хәрәкәт формалаштыру | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 2.1. | Татарстан Республикасы оешмалары һәм предприятиеләре хезмәткәрләренең сәламәтлеген ныгыту мәсьәләләре буенча федераль һәм республика норматив хокукый актларны, оештыру хатларын һәм методик документларны кертү | 01.01.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» ДАССУ, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының территориаль сәламәтлек саклау идарәләре җитәкчеләре, Татарстан Республикасы медицина оешмаларының, шул исәптән зурлар өчен 15 сәламәтлек үзәгенең баш табиблары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | Татарстан Республикасы оешмалары һәм предприятиеләре хезмәткәрләренең сәламәт яшәү рәвеше алып баруга, тәмәке тартудан баш тартуга, алкоголь куллануны киметүгә, рациональ туклануга, физик активлыкны арттыруга мотивация формалаштыру чараларын гамәлгә ашыру |
| 2.2. | Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Дәвалау һәм профилактика медицинасы буенча милли медицина тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан эшләнгән методик тәкъдимнамәләр нигезендә Татарстан Республикасы оешмалары һәм предприятиеләре хезмәткәрләренең сәламәтлеген ныгыту буенча яңартылган корпоратив программаларны кулланышка кертү, әлеге программаларга хезмәткәрләрдә | 01.03.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, дүрт җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы үзәге, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | Татарстан Республикасы оешмалары һәм предприятиеләре хезмәткәрләренең сәламәт яшәү рәвеше алып баруга, тәмәке тартудан баш тартуга, алкоголь куллануны киметүгә, рациональ туклануга, физик активлыкны арттыруга мотивация формалаштыру чараларын гамәлгә ашыру |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | сәламәт яәзү рәвешен һәм аларның сәламәтлегенә рискларны киметә торган үз тотышны формалаштыру юлы белән аларның сәламәтлеген саклауга һәм ныгытуга, аларның эшкә сәләтен арттыруга һәм яшәү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән оештыру, профилактика, савыктыру, социаль-икътисадый һәм башка чаралар комплексы керә. | | | | |
| 2.3. | Зурлар өчен сәламәтлек үзәкләре тарафыннан эш урынында эшләүче гражданнарны тикшерүне, шулай ук авырулар үсешендә ачыкланган рискларга ия затларга эш урынында диспансер күзәтүен оештыру | 01.03.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының территориаль сәламәтлек саклау идарәләре җитәкчеләре, Татарстан Республикасы медицина оешмаларының, шул исәптән зурлар өчен 15 сәламәтлек үзәгенең, «Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» ДАССУ баш табиблары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | 2025 елда – 40 441 кеше;<br>2026 елда – 53 921 кеше;<br>2027 елда – 80 881 кеше;<br>2028 елда – 107 842 кеше;<br>2029 елда – 134 802 кеше;<br>2030 елда – 161 762 кеше |
| III. Алкоголь продукциясен артык куллану масштабларын киметү һәм алкоголизмны профилактикалау чаралары | | | | | |
| 3.1. | Алкоголь продукциясен артык куллануны профилактикалау мәсьәләләре буенча федераль һәм республика норматив | 01.01.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Татарстан Республикасы | Татарстан Республикасы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен алып баруга мотивация булдыру, алкоголь куллануны киметү чараларын гамәлгә ашыру |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | хокукый актларын, оештыру хатларын һәм методик документларны кертү | | | Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник наркология диспансеры» ДАССУ, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының наркология буенча штаттан тыш баш белгече, «Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» ДАССУ, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының территориаль сәламәтлек саклау идарәләре җитәкчеләре, Татарстан Республикасы медицина оешмаларының, шул исәптән зурлар өчен 15 сәламәтлек үзәгенең баш табиблары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | |
| 3.2. | Татарстан Республикасы кызыксынучы республика башкарма хакимият органнары, җәмәгать һәм социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар белән алкоголь продукциясен артык куллануны профилактикалау мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек | 01.01.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник наркология диспансеры» ДАССУ, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының наркология буенча штаттан тыш баш белгече, «Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» ДАССУ, Татарстан Республикасы Сәламәтлек | Татарстан Республикасы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен алып баруга мотивация булдыру, алкоголь куллануны киметү чараларын гамәлгә ашыру |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | саклау министрлыгының территориаль сәламәтлек саклау идарәләре җитәкчеләре, Татарстан Республикасы медицина оешмаларының, шул исәптән зурлар өчен 15 сәламәтлек үзәгенең баш табиблары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | |
| 3.3. | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, Татарстан Республикасының кызыксынучы республика башкарма хакимият органнары белән берлектә, алкоголь продукциясен артык куллануның проблемалы мәсьәләләре буенча аң-белем бирү чаралары үткәрү, радио һәм телетапшырулар (сюжетлар) ясау, массакүләм матбугат чараларында язмалар бастырып чыгару | 01.01.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник наркология диспансеры» ДАССУ, «Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» ДАССУ, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының территориаль сәламәтлек саклау идарәләре җитәкчеләре, Татарстан Республикасы медицина оешмаларының, шул исәптән зурлар өчен 15 сәламәтлек үзәгенең баш табиблары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | Халык арасында, шул исәптән балалар һәм яшьләр арасында, тәмәке һәм башка никотинлы продукция куллануга каршы профилактик чараларны гамәлгә ашыру |
| IV. «Әйләнә-тирәдәге тәмәке төтене йогынтысыннан, тәмәке куллану яисә никотинлы продукция куллану зыяннарыннан гражданнарның сәламәтлеген саклау турында» 2013 елның 23 февралендәге 15-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 4.1. | Халык арасында тәмәке тартуга һәм никотинлы башка продукция куллануга каршы тору мәсьәләләре буенча федераль һәм республика норматив хокукый актларын, оештыру хатларын һәм методик документларны кертү | 01.01.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник наркология диспансеры» ДАССУ, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының наркология буенча штаттан тыш баш белгече, «Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» ДАССУ, зурлар өчен 15 сәламәтлек үзәгенең баш табиблары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | Халык, шул исәптән балалар һәм яшьләр арасында тәмәке тартуга һәм никотинлы башка продукция куллануга каршы тору буенча профилактик чараларны гамәлгә ашыру |
| 4.2. | Тәмәке тартуга һәм никотинлы башка продукция куллануга каршы тору буенча Татарстан Республикасының кызыксынучы республика башкарма хакимият органнары, иҗтимагый һәм социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү | 01.01.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник наркология диспансеры» ДАССУ, дүрт җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы үзәге, зурлар өчен 15 сәламәтлек үзәге, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | Халык, шул исәптән балалар һәм яшьләр арасында тәмәке тартуга һәм никотинлы башка продукция куллануга каршы тору буенча профилактик чараларны гамәлгә ашыру |
| 4.3. | Республика «Татмедиа» матбу- | 01.01.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, | Халыкка тәмәкенең һәм никотинлы башка продукциянең зыяны турында |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | гат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, республиканың башка кызыксынучы оешмалары белән берлектә, халык, шул исәптән балалар һәм яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвеше, тәмәке тартуга һәм никотинлы башка продукция куллануга каршы тору мәсьәләләре буенча аң-белем бирү чаралары үткәрү, радио һәм телевизион тапшырулар (сюжетлар) ясау, матбугатта язмалар бастырып чыгару | | | «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник наркология диспансеры» ДАССУ, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының наркология буенча штаттан тыш баш белгече, «Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» ДАССУ, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | (хокукый чараларны, аерым урыннарда тәмәке тартуга тыюларны кертеп) мәгълүмат бирү, сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыру |
| V. Массакүләм физик культураны үстерү чаралары | | | | | |
| 5.1. | Массакүләм физик культураны үстерү мәсьәләләре буенча федераль һәм республика норматив хокукый актларын, оештыру хатларын һәм методик документларны кертү | 01.01.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» ДАССУ, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының спорт медицинасы буенча штаттан тыш баш белгече, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | Физик культура һәм спорт өлкәсендә халык сәламәтлеген саклау |
| 5.2. | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка кызыксынган рес- | 01.01.2025 | 31.12.2026 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, дүрт җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы үзәге, Татарстан Республикасы Сәламәтлек | Татарстан Республикасында табиб-физкультура эшчәнлеген үстерү |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | публика органнары катнашында 2023 – 2026 елларга Татарстан Республикасында спорт медицинасын үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру | | | саклау министрлыгының спорт медицинасы буенча штаттан тыш баш белгече, Татарстан Республикасы медицина оешмаларының баш табиблары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | |
| 5.3. | Спорт чараларын, шул исәптән «Хезмәткә һәм оборонага әзер» бөтенроссия физкультура-спорт комплексы сынаулары (тестлары) нормативларын үтәү кысаларында билгеләнгән тәртиптә оештыруда һәм үткәрүдә катнашу | 01.01.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы медицина оешмаларының, шул исәптән «дәвалау физкультурасы һәм спорт медицинасы» профиле буенча беренчел махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларының баш табиблары | Физик культура һәм спорт өлкәсендә халык сәламәтлеген саклау |
| 5.4. | «Һәр муниципалитетка – акыллы сәламәтлек маршруты» проектында, шул исәптән «Яшәү өчен 10 000 адым» һәм «Йөрү көне» бөтенроссия акциясенең төбәк этапларын үткәрүдә катнашу | 01.01.2025 | 31.12.2030 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, дүрт җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы үзәге, Татарстан Республикасы медицина оешмаларының баш табиблары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | Халыкның физик активлыгын арттыру, сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен пропагандалау |

Төбәк программасының ресурслар белән тәэмин ителеше

Акча «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү»Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Һәркем өчен сәламәтлек (Татарстан Республикасы (Татарстан))» төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында каралды:

барлыгы – 35 626,2 мең сум, шул исәптән:

2025 ел – 16 100,6 мең сум, 2026 ел – 8 242,1 мең сум, 2027 ел – 10 496,2 мең сум, 2028 ел – 787,3 мең сум, 2029 ел – 0,0 мең сум, 2030 ел – 0,0 мең сум.

шулардан:

федераль бюджет акчасы – 26 248,8 мең сум, шул исәптән:

2025 ел – 12 719,5 мең сум, 2026 ел – 6 016,7 мең сум, 2027 ел – 7 032,4 мең сум, 2028 ел – 480,2 мең сум, 2029 ел – 0,0 мең сум, 2030 ел – 0,0 мең сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 9 377,4 мең сум, шул исәптән:

2025 ел – 3 381,1 мең сум, 2026 ел – 2 225,4 мең сум, 2027 ел – 3 463,8 мең сум, 2028 ел – 307,1 мең сум, 2029 ел – 0,0 мең сум, 2030 ел – 0,0 мең сум.